Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Аппак авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2023 ел №90

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

Аппак авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 30 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2023 елның 20 февралендәге 66 номерлы, 2023 елның 1 августындагы 80 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләргә классьы чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә аларны саклап калу тәртибе» 4 бүлегендә карарга кушымталар:

- 4.6 пунктындагы 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 4.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә классьы чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән классьы чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Аппак авылы, Тынычлык урамы, 71 нче йорт; Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Аппак авыл җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова